РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.09.2020 № 1248-па

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы бюджетыннан минераль ашламалар
сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен
финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү
тәртибен раслау турында” 2019 елның
2 апрелендәге 316-п номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгын һәм сыйфатын арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2019 елның 2 апрелендәге 316-п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “агымдагы финанс елының 1 августына кадәр (2020 елгы көзге уңыш өчен кертелгән минераль ашламаларны да исәпкә алып) агымдагы финанс елының барлык авыл хуҗалыгы культураларының 1 гектар чәчүлек мәйданнарына кимендә 45 кг минераль ашлама сатып алырга.”;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр 2020 ел уңышы өчен һәм 2020 елгы көзге уҗымнар өчен сатып алынган минераль ашламалар бәясенең 65% күләмендә НДС һәм транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча бирелә;

1.3. 6 пунктны төшереп калдырырга;

1.4. 7 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“агымдагы финанс елның 1 августына кадәр (2020 елгы көзге уңыш өчен кертелгән минераль ашламаларны да исәпкә алып) агымдагы финанс елының барлык авыл хуҗалыгы культураларының 1 гектар чәчүлек мәйданнарына

кимендә 45 кг минераль ашлама сатып алуны раслаучы документлар күчермәләре (тәэмин итү килешүе, түләү йөкләмәләре яки башка документлар).”;

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов